

Бvген кибет тулы сот ризыклары, сатасын да аласын. Житмәсә, сотләре дә тиз генә әчеми. Бер алганы атналар буена житәргә момкин. Тик сонгы арада тикшерv органнары халыкны куркуга сала торган мәгълvматлар житкерә башлады.
Кvптән тvгел генә Россельхознадзор идарәсе Россия сәvдә нокталарына сатуга чыгарылган соттә судан тыш сода, крахмал, акбур, известь, бор яки салицил кислотасы, хәтта гипс барлыгын белдергән. Тикшерvләрне Россельхознадзор идарәсе каршында эшләп килvче “ВНИИЗЖ” оешмасы vткәргән. Анализлар кvрсәткәнчә, каймакны еш кына кефир, майсыз эремчеккә алмаштыралар икән. Анын составынданиләр генә юк. Yсемлек мае, сыйфатсыз сот кушылмалары, соя аксымы, крахмал, тәм остәгечләр... Yсемлек майларын шулай ук эремчек, атланмай, сырга да кушалар. Гадәттә, мондый майнын ин арзанлысын остиләр, дип чан суга белгечләр. Моннан тыш кулланылышка “атланмайны алмаштыручы” дигән яна гыйбарә дә килеп кергән. Житештерvчеләр кvп чыгым тотмыйча гына зур керем алуны максат итеп куя, шуна кvрә теләсә нинди адымга бара. Андыйларнын, билгеле, сот ризыклары да арзанга чыга. Ә чын товар житештерvчеләргә исә алар белән кондәшлек алып бару бик кыен.
Безнен республикада да белгечләр мондый очракларга юлыга икән; әмма сирәк. Мәсәлән, әле генә Мордовия һәм Пенза олкәсе Россельхознадзор Идарәсе Хокvмәт инспекторы белән оештырылган тикшерv буенча (приказ Федеральной службы по ветеринарному и фитосанитарному надзору от 06.04.2016 года №200 «О проведении проверок», изданного в соответствии с протоколом заседания Правительственной комиссии по мониторингу и оперативному реагированию на изменение конъюнктуры продовольственных рынков от 1 марта 2016 года №1) Ковылкино районы “Созидание” авыл хужалыгы коооперативы сотне дорес шартларда савып, ветеринар-санитар таләпләргә туры китереп «Молочный комбинат «Саранский» АО «Данон Россия»гә тапшыралар. Документлары да дорес тутырылган. Әмма сот ашамлыкларынын, шул исәптән сырларнын да, килеп чыгышы, саклану датасы булмаган очракка тап булганнар һәм Пролетар районы шәхси эшмәкәренен (Федосеева А.М.) сатучысына бер мен сум кvләмендә штраф та салганнар. Россельхознадзор идарәсендә белдерvләренчә, акбур, гипс, известь кушылган очракларга, шокер, юлыкканнары юк икән.
Роспотребнадзор идарәсе тикшерv-ләрнен нәтижәсен ай саен рәсми сайтларына урнаштырып баруларын белдерде. Май аенда, мәсәлән, таләпләргә жавап бирмәгән дvрт очракны ачыклаганнар. Ике житештерvченен каймагы, бер эремчек, бер куертылган сот ялган сот ризыклары исемлегенә кертелгән. Болар – “Кулебакский

молочный завод” (Түбән Новгород өлкәсе), “Южский молочный завод” (Иваново), “Промконсервы” (Смоленск),  “Айсберг Люкс” (Мәскәү) җәмгыятьләре җитештергән ризыклар. Болай булгач, сөт өчен сыер кирәкми инде...

**Наилә Насырова**